# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТА ТОРГАН ГОМУМИ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН «ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)» ФӘНЕННӘН ҮРНӘК ПРОГРАММА (5-9 СЫЙНЫФЛАР)

**Төзүче-авторлар: Г.Р.Галиуллина**
**М.М.Шәкурова**

**Казан-2016**

**Программаның эчтәлеге**

Татар телендә укыта торган гомуми урта белем бирү оешмалары өчен «Туган тел (Татар теле)» фәненнән үрнәк программа (5-9 сыйныфлар)……………………………………………………………………………………….3

Уку фәнен өйрәнүдән көтелгән нәтиҗәләр ……………………………………………………………………..3

Уку фәненең эчтәлеге………………………………………………………………………………………………..6

Һәр теманы үзләштерү өчен кирәкле сәгатьләр саны күрсәтелгән һәм уку эшчәнлегенең төрләре күрсәтелгән календарь-тематик план………………………………………………………………….……………………9

Татар телендә укыта торган гомуми урта белем бирү оешмалары өчен «Туган тел (Татар теле)» фәненнән үрнәк программа (10-11 сыйныфлар)……………………………………………………………………………..………

Уку фәнен өйрәнүдән көтелгән нәтиҗәләр ……………………………………………………….…………..

Һәр теманы үзләштерү өчен кирәкле сәгатьләр саны күрсәтелгән уку фәненең эчтәлеге..............................................

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ УКЫТА ТОРГАН ГОМУМИ УРТА БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН «ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)» ФӘНЕННӘН ҮРНӘК ПРОГРАММА (5-9 СЫЙНЫФЛАР)

## ФӘННЕ ӨЙРӘНҮНЕҢ ЯКЫНЧА НӘТИҖӘЛӘРЕ

5-9 нчы сыйныфларда татар теленнән уку курсын үзләштерү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

**1) Шәхескә кагылышлы нәтиҗә:**

- Татар халкының милли-мәдәни кыйммәтләренең берсе буларак татар телен аңлау; шәхеснең интеллектуаль, иҗади сәләтләрен һәм әхлак сыйфатларын үстерүдә туган телнең мөһим ролен, мәктәптә белем алу процессында ана теленең әһәмиятен аңлау.
- Татар теленең эстетик кыйммәтен аңлау; туган телгә карата хөрмәт, аның белән горурлану; милли мәдәният күренеше буларак татар теленең чисталыгын саклау ихтыяҗы; сөйләм культурасында үзүсешкә омтылу;
- Сөйләшү процессында фикер һәм хисләрне иркен белдерү өчен сүзлек запасының һәм үзләштерелгән грамматик чараларның җитәрлек күләмдә булуы.

**2) Метапредмет нәтиҗәләр:**

- сөйләмнең барлык төрләренә ия булу:
- телдән сөйләшүне һәм язма хәбәрләрне тиешенчә аңлау;
- укуның барлык төрләренә ия булу;
- төрле стиль һәм жанрдагы текстларны тыңлап тиешенчә кабул итү;
- мәгълүматны төрле чыганаклардан, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, уку-укыту процессы өчен дип әзерләнгән компакт-дисклардан, Интернет ресурсларыннан таба алу, төрле сүзлекләрдән, әдәбияттан файдалана белү.
- мәгълүматны сайлап алу һәм билгеле бер темаларга аеру, системалаштыру алымнарына ия булу;

- сөйләм текстларын эчтәлек, стилистик үзенчәлекләр һәм кулланылган тел берәмлекләре буенча чагыштыра һәм тәңгәлләштерә белү;
- алда торган шәхси һәм коллектив уку эшчәнлегенең максактларын, эш-гамәлләр эзлеклелеген, шулай ук ирешелгән нәтиҗәләрне билгели белү һәм аларны телдән, язма формада тиешенчә тәгъбир итү;
- төрле катлаулылыктагы сөйләмә һәм язма текстларны сөйләп бирә белү;
- төп фикер, адресат һәм аралашу ситуациясен исәпкә алып, төрле типтагы, төрле стильдәге һәм жанрдагы сөйләмә һәм язма текстлар төзү;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада иркен һәм дөрес итеп тәкъдим итү;
- монолог һәм диалогның бөтен төрләрен дә үзләштерү;
- сөйләм практикасында хәзерге әдәби татар теленең төп орфоэпик, лексик, грамматик, стилистик нормаларын саклау; язма формада аралашу вакытында төп орфографик кагыйдләрне һәм пунктуация таләпләрен үтәү;
- сөйләм этикетын саклап, телдән аралашуда катанаша алу сәләте;
- үз сөйләмеңне эчтәлек һәм тел бизәкләре ягыннан бәяләү; грамматик һәм сөйләм хаталарын, төгәлсезлекләр табу һәм аларны төзәтү; үзең төзегән текстларны төзәтә һәм камилләштерә белү;
- яшьтәшләрең каршында зур булмаган хәбәр һәм докладлар белән чыгыш ясый алу;
- алган белем-күнекмәләрне көндәлек тормышта кулана һәм башка фәннәрдән белем алганда туган телдән файдалана белү, алган белемнәрне фәнара дәрәҗәдә файдалану (чит тел, әдәбият дәресләре һ.б.);
- Сөйләшү, нинди дә булса биремне бергәләшеп үтәү, бәхәс һәм тикшерүләрдә катнашу вакытында әйләнә-тирәдәгеләр белән максатчан рәвештә коммуникатив бәйләнешкә керү; формаль һәм формаль булмаган шәхесара һәм мәдәниятара аралашуның милли-мәдәни нормаларын үзләштерү.

**3) Предмет нәтиҗәләре:**

- телнең төп функцияләре турында, Татарстан Республикасының дәүләт теле һәм татар халкының милли теле буларак татар теленең әһәмияте турында, тел һәм мәдәният арасындагы бәйләнеш, кеше һәм җәмгыять тормышында туган телнең әһәмияте турында күзаллау;
- туган телнең гуманитар фәннәр системасындагы урынын һәм гомумән белем бирү өлкәсендәге әһәмиятен аңлау;

- туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен үзләштерү; аның баскычлары һәм берәмлекләре арасындагы бәйләнешне аңлау;
- лингвистиканың төп төшенчәләрен үзләштерү: лингвистика һәм аның төп бүлекләре; тел һәм сөйләм, аралашу, телдән һәм язмача аралашу; монолог, диалог һәм аларның төрләре; телдән аралашу ситуациясе; сөйләм теле, фәнни, публицистик, рәсми стильләр, әдәби тел; фәнни, публицистик һәм рәсми эш кәгазьләре жанрлары;
- сөйләмнең функциональ-мәгънәви төрләре (хикәяләү, сурәтләү, фикерләү); текст, текст төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның билгеләре һәм сөйләмдә куллану үзенчәлекләре;
- татар теле лексикасы һәм фразеологиясенең төп стилистик чыганакларын, әдәби татар теленең төп нормаларын (орфоэпик, орфографик, пунктуацион), сөйләм этикасы нормаларын үзләштерү; аларны язма һәм телдән сөйләм вакытында куллану;
- телнең төп берәмлекләрен, грамматик категорияләрен тану һәм анализлау, сөйләм ситуацияләре вакытында тел берәмлекләрен урынлы куллану;
- сүзгә төрле төрдәге анализлар ясау (фонетик, морфемик, сүзьясалыш, лексик, морфологик), сүзтезмә һәм җөмләгә синтаксик анализ; аңа  төп билгеләре һәм структурасы, телнең билгеле бер функциональ төрләргә каравы, тел бизәкләрен кулланылуы, телнең тәэсирлелек чараларыннан файдалануы ягыннан күп аспектлы анализ;
- лексик һәм грамматик синонимиянең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен аңлау һәм аларны үзеңнең сөйләмеңдә файдалану;
- Татар теленең эстетик функциясен аңлау, әдәби әсәр текстларын анализлау вакытында сөйләмнең эстетик якларын бәяләү сәләте.

## «ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)» ФӘНЕНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

**Татар теле турында гомуми мәгълүмат.**

Аралашу чарасы буларак тел. Телнең төп функцияләре. Кеше тормышында һәм үсешендә туган телнең роле.

Тугандаш һәм тугандаш булмаган телләр. Татарлар яши торган регионнар. Кеше һәм җәмгыять тормышында телнең роле.

**Фонетика һәм орфоэпия**.

Лингвистика бүлеге буларак фонетика һәм орфоэпия. Сөйләм органнары, сөйләм авазлары булдыруда аларның урыны. Аваз. Фонема. Татар теленең сузык авазлар системасы, аларның саны. Сузык авазларның классификациясе. Татар теленең сузык авазлар системасындагы үзгәрешләр. Сингармонизм законы, аның төрләре. Сузык авазларның кыскаруы. Дифтонглар. Татар телендә тартыклар, аларның саны. Тартык авазлар классификациясе. Татар теленең тартык авазлар системасындагы үзгәрешләр. Тартыкларның ассимиляциясе, ассимиляция төрләре. Татар һәм рус телләрендә тартык һәм сузык авазлар.

Татар телендә басым. Татар теленең үз сүзләрендә һәм алынмаларда басымның сакланмау очраклары. Интонация төшенчәсе.

Әдәби тел нормалары. Орфоэпия нормалары төшенчәсе. Орфоэпик сүзлек.

Фонетик анализ.

**Графика, орфография.**

Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Татар теле алфавиты.

Орфография. Сузыкларның язылышы. Тартыкларның язылышы. Ике аваз белдерә торган хәрефләрнең язылышы. “ъ” һәм “ь” билгеләренең язылышы.

Орфографик сүзлек. Телнең орфографик нормалары.

**Морфемика (телнең морфем төзелеше) һәм сүз ясалышы.**

Сүзнең барлыкка килүе һәм төзелеше турында гомуми мәгълүмат. Телнең иң кечкенә мәгънәле кисәге буларак морфема. Тамыр һәм аффикс. Тамырдаш сүзләр. Аффикслар ярдәмендә яңа сүз ясау. Аларның төрле сүз төркеменә караган сүзләр ясалышындагы роле.

Аффикслар, аффикс төрләре: сүзъясагыч һәм модаль аффикслар. Тамыр һәм ясалма нигезләр.

Татар телендә сүз ясау ысуллары. Тамыр сүзләр. Ясалма сүзләр, ясалма сүзләрнең структур төрләре: кушма, тезмә, парлы.

Татар һәм рус телләрендә сүз төзелешендәге төп аермалар.

Этимология төшенчәсе.

Сүз ясалышы ягыннан һәм морфемик анализ.

**Лексикология һәм фразеология.**

Телнең төп берәмлеге буларак сүз. Сүзнең лексик берәмлеге. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр. Антонимнар, синонимнар, паронимнар, омонимнар һәм аларның төрләре.

Төрки-татар чыгышлы сүзләр һәм алынмалар.

Татар теленең сүзлек составы: архаизмнар, тарихи сүзләр, неологизмнар һәм аларның төрләре. Диалектизмнар. Терминнар һәм һөнәрчелек сүзләре. Жаргон сүзләр.

Фразеологизмнар, аларның төрләре. Сөйләмдә фразеологизмнарны куллану үзенчәлекләре.

Төрле төрдәге сүзлекләр, аларны төрле эшчәнлектә файдалану.

Татар теленең төп лексик нормалары. Сүзгә лексик анализ ясау.

**Морфология.**

Сүзләрнең лексик-грамматик төрләре буларак сүз төркемнәре. Сүз төркемнәренең классификациясе. Мөстәкыйль, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәре. Аларның семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре. Төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр ясау, аларның семантикасы һәм кулланылыш үзенчәлеге.

Татар теленең төп морфологик нормалары .

Сүзгә морфологик анализ ясау.

**Синтаксис.**

Синтаксис турында гомуми мәгълүмат. Сүзтезмә һәм җөмлә. Җөмләдә синтаксик бәйләнеш. Тезүле һәм ияртүле бәйләнеш.

Җөмлә. Җөмлә кисәкләре, баш һәм иярчен кисәкләр. Җөмләдә сүз тәртибе.

Гади җөмлә төрләре. Җәенке һәм җыйнак җөмләләр. Тулы һәм тулы булмаган җөмләләр. Сөйләмдә бер составлы җөмләләрне куллану үзенчәлеге.

Раслау һәм инкарь җөмләләр турында гомуми мәгълүмат.

Туры һәм кыек сөйләм. Диалог, диалогта тыныш билгеләренең куелышы.

Кушма җөмлә төшенчәсе. Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.

Иярченле кушма җөмлә төшенчәсе. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмлә төзелеше. Синтетик иярченле кушма җөмлә, әлеге төр җөмләләрдә бәйләнеш төрләре, тыныш билгеләре. Аналитик иярченлек кушма җөмлә, бәйләнеш төрләре һәм тыныш билгеләре.

Иярчен җөмләләр, аларның төрләре. Төрле юл белән бәйләнгән кушма җөмләләр.

Текст синтаксисы турында гомуми мәгълүмат.

Телнең төп синтаксик нормалары.

Синтаксик анализ.

**Пунктуация.**

Татар телендә тыныш билгеләре. Ия һәм хәбәр арасында сызык куелу очраклары. Аерымланган иярчен кисәкләр, эндәш һәм кереш сүзләр булган җөмләләрдә тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр булган очракта тыныш билгеләренең куелышы.

Диалог, диалогта тыныш билгеләренең куелышы. Туры сөйләм булган җөмләләрдә тыныш билгеләре.

Кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.

**Стилистика һәм сөйләм культурасы.**

Телдән һәм язма сөйләм төшенчәсе. Сөйләмдә синоним, антоним һ.б. дөрес куллану. Сөйләм культурасын үстерү һәм стильне камилләштерүдә синтаксик синонимнарның роле.

Сөйләм культурасы төшенчәсе. Сөйләм һәм язма әдәби сөйләмгә карата таләпләр турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмдә төрле лексик чаралар (синоним, антоним, калькалар, фразеологик әйтелмәләр, мәкальләр һәм әйтемнәр) куллану мөмкинлеге.

**Тел һәм мәдәният.**

Татар теленең сөйләм этикеты. Коммуникация төренә карап, тиешле сөйләм этикеты нормаларын куллану.

Милли-мәдәни компонентлы мәгънә йөрткән тел берәмлекләрен таный һәм аларның мәгънәләрен аңлатмалы, этимологик, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге һәм башка сүзлекләр ярдәмендә аңлата белү.

## Һәр теманы үзләштерү өчен кирәкле сәгатьләр саны һәм уку эшчәнлегенең төп төрләре күрсәтелгән **календарь-тематик план**.

**5 сыйныф**

| **Барлык сәгатьләр саны** | **105 сәг.** |
|---|---|
| Коммуникатив компетенция | 25 сәг. |
| Тел һәм лингвистик компетенция | 72 сәг. |
| Этномәдәни компетенция | 8 сәг. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| 1. КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯ БУЛДЫРУНЫ ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН ЭЧТӘЛЕК (25 сәг) | | | |
| **5** | Сөйләм һәм аралашу | Аралаша белү – кеше мәдәниятенең әһәмиятле өлеше.<br>Сөйләм һәм аралашу. Сөйләм ситуациясе. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Монолог төрләре: хикәяләү, сурәтләү, фикерләү. | Аралашу ситуациясен һәм шартларын, сөйләүченең коммуникатив максатларын күзаллау.<br>Телдән һәм язма сөйләмнең төп үзенчәлекләре турында күзаллау.<br>Телдән һәм язма сөйләм үрнәкләрен аеру.<br>Диалогик һәм монологик сөйләм үрнәкләрен аеру.<br>Диалог һәм монолог төрләре (хикәяләү, сурәтләү, фикерләү) турында күзаллау. |
| **5** | **Сөйләм эшчәнлеге** | Эшчәнлек төре буларак сөйләм. Сөйләм эшчәнлеге төрләре: тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу. Аралашу шартларына тәңгәл рәвештә укыган, тыңлаган, күргән мәгълүмат эчтәлеген сайлап алып, кыскача һәм җентекләп сөйләү. Дәреслектә күрсәтелгән сылтамалар буенча Интернет челтәрләрендә мәгълүмат эзләү. | Сөйләм төрләре турында гомуми күзаллауга ия булу. Тексттагы төп мәгълүматны күреп яки ишетеп кабул итү. Тыңлап аңлау төрләреннән файдалану (сайлап алынган яки таныштыру аудиоязмалары). Төрле чыганаклардан алынган мәгълүматны табу, аны, аралашу шартларына туры китереп, тәкъдим итү һәм тапшыру. |

| **Сәгатьләр саны** | **Бүлек исеме , тема** | **Төп эчтәлеге** | **Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика** |
|---|---|---|---|
| **4** | **Текст** | Сөйләм эшчәнлеге продукты буларак текст. Текст төшенчәсе. Текст темасы, төп мәгънә. Текст микротемасы. Текст кисәкләре һәм җөмләләрне бәйләүче лексик һәм грамматик чаралар. Текст планы (гади).<br>Хикәяләү (хикәя, сөйләү), сурәтләү (предметне, халәтне), фикерләү, аларның төп үзенчәлеге. | Текст билгеләрен белү. Текст темасын, төп мәгънәсен, иң мөһим сүзләрне билгеләү. Текстның микротемасын билгеләү, аны кызыл юлларга бүлү. Абзацның һәм текстның композицион элементларын (кереш, төп өлеш, йомгак) белү. Текст кисәкләре һәм җөмләләрне бәйләүче лексик һәм грамматик чараларны табу.<br>*Үз тәкъдимеңне дәлилләп, текстка исем бирергә*.<br>Тема бердәмлеге, хикәяләү эзлеклелегеннән чыгып, текстны анализлау һәм характеристика бирү. |
| **2**<br><br><br><br><br><br>**14 сәг.** | Сөйләм теле<br><br><br><br><br><br>Контроль диктант (4).<br>Изложение (5).<br>Инша (5) | Сөйләм телен куллану даирәсе, аралашуның типик ситуацияләре. | Сөйләм теле һәм әдәби әсәр теле үрнәкләрен аеру. Коммуникатив таләпләр, тел нормаларына туры килү күзлегеннән чыгып, үзеңнең һәм башкаларның сөйләмнәрен бәяләү.<br>Сөйләмдәге төгәлсезлекләрне төзәтү.<br>Татар теленең орфографик нормаларын үтәп, контроль диктант, изложение, инша; инша элементлары кертеп изложение язу; орфографик, пунктуацион хаталар табу һәм аларны төзәтү. |
| 2. ТЕЛ ҺӘМ ЛИНГВИСТИК КОМПЕТЕНЦИЯ ЯСАЛЫШЫН ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН ЭЧТӘЛЕК (70 сәг.) | | | |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| 1 сәг. | **Татар теле турында гомуми мәгълүмат.** | Аралашу чарасы буларак тел. Татар теле — татар әдәби әсәрләр теле. Тел турындагы фән буларак лингвистика. Лингвистиканың төп бүлекләре (гомуми мәгълүмат). | Телләр турында күзаллауга ия булу, татар теленең Россия тарихы һәм мәдәнияте белән бәйләнешне аңлау; хәзерге татар теленең төп кулланылыш формалары турында күзаллауга ия булу.<br>Телнең җәмгыять һәм дәүләт тормышындагы ролен аңлау; телнең кеше тормышындагы роле.<br>Лингвистиканың төп бүлекләре турында күзаллау булу. |
| **3 ч.** | Башлангыч сыйныфта үткән материалны кабатлау. | Аваз. Татар теленең сузык авазлар системасы. Сузыкларның язылышы. Тартыкларның язылышы. Телнең орфографик кагыйдәләре. Сүзнең лексик мәгънәсе. Сүз ясалышы һәм сүз формасы үзгәрү. Грамматиканың бер бүлеге буларак морфология. Синтаксис берәмлеге буларак сүзтезмә. Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. Аларның интонацион һәм мәгънәви үзенчәлекләре. | Телдән һәм транскрипция элементлары ярдәмендә анализлау һәм характеристика бирү: сөйләмнең аерым авазларын, сүзләрне әйтү һәм язу үзенчәлекләре; сөйләмдә авазлар; иҗекләргә бүлү күзлегеннән сүз; орфографик хаталар табу һәм аларны төзәтү; сүз төркемнәренең синтаксик ролен билгеләү; сүзгә морфологик анализ ясау. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| **10** | Фонетика һәм графика. | Лингвистика бүлеге буларак фонетика. Сөйләм органнары, аларның сөйләм авазлары булдыруда катнашуы. Татар теленең сузык авазлар системасы, аларны күләме. Сузык авазларның классификациясе. Татар теленең сузык авазлар системасындагы үзгәрешләр. Сингармонизм законы, аның төрләре. Сузыкларның кыскаруы. Дифтонглар. Татар телендә тартыклар, аларның күләме. Татар теленең тартыклар системасындагы үзгәрешләр. Тартыклар ассимиляциясе, ассимиляция төрләре. Татар һәм рус телләрендә сузык һәм тартык авазлар. Интонация төшенчәсе. Татар телендә басым. Татар теленең үз сүзләрендә һәм алынмаларда басым сакланмау очраклары. Сүз формаларында басым куюның авыр | Авазның мәгънә аеру функциясен аңлау. Сөйләм аппаратының төзелешен, татар телендәге авазлар ясалу ысулларын аңлау. Сөйләмдәге аерым авазларга, сүзләрнең әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләренә, сөйләм агымындагы авазларга, иҗекләргә бүлү күзлегеннән чыгып сүзгә телдән һәм транскрипция элементлары ярдәмендә анализ ясау һәм характеристика бирү.<br>Сүзгә фонетик анализ ясау.<br>Сузыкларны һәм тартыкларны тану; басымлы һәм басымсыз сузыклар; шаулы тартыклар (яңгырау һәм саңгырау) һәм сонор тартыклар; сингармонизм законы, аның төрләре.<br>Бирелгән күрсәткечләр буенча сөйләм авазларын, аваз составы параметрлары буенча сүзләрне классификацияләү һәм төркемнәргә бүлү; басымлы иҗек урынын билгеләү, сүз формасы үзгәргәндә басымның үзгәрешен күзәтү.<br>Акцентлаштыру күзлегеннән кыен булган сүзләрдә һәм аларның формаларында (боерык фигыльләр һ.б.) кабул ителгән басым төшү урынын үзләштерү. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | | очраклары. | |
| **8** | Орфоэпия һәм орфография. | Әдәби тел нормалары. Орфоэпия нормалары төшенчәсе. Орфоэпик сүзлек. Фонетик анализ.<br>Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Татар теле алфавиты. Орфография. Сузыкларның язылышы. Тартыкларның язылышы. Ике авазны белдерә торган хәрефләрнең язылышы. “ъ” һәм “ь” билгеләренең язылышы.<br>Орфографик сүзлек. Телнең орфографик нормалары.<br>Кабатлау. | Кыскартылган сүзләрне дөрес әйтү. Орфоэпик сүзлекне файдалану.<br>Сүзнең аваз һәм хәреф составын чагыштыру һәм анализлау: мәгълүмат эзләгәндә алфавитны белеп файдалану; орфографик сүзлекләрне файдалану; орфографик хаталарны табу һәм төзәтү; татар теленең орфографик кагыйдәләрен истә тотып, контроль диктант, изложение, инша, инша элементлары кертелгән изложение язу; сүзгә фонетик һәм орфоэпик анализ ясау. Сүзләрдә өйрәнелгән орфограммалар табу. Өйрәнелгән орфограммаларга характеристика бирү һәм сүзләрнең язылышын аңлату. |
| **15** | **Лексикология һәм фразеология** | Лингвистиканың бер бүлеге буларак лексикология.<br>Телнең төп берәмлеге буларак сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер | Сүзгә лексик анализ ясау; сүзнең лексик мәгънәсен һәм дөрес язылышын аңлату өчен килеп чыгышы турындагы мәгълүматны файдалану. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, туры һәм |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | | мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе. Антоним, синоним, пароним, омонимнар һәм аларның төрләре.<br>Татар теленең үз сүзләре һәм алынмалар.<br>Татар теленең сүзлек составы. Актив һәм пассив лексика. Искергән сүзләр һәм неологизмнар.<br>Фразеологизмнар, аларның мәгънәләре. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрне куллану үзенчәлекләре.<br>Төрле төр сүзлекләр, аларны төрле эшчәнлек вакытында файдалану.<br>Татар теленең төп лексик нормалары.<br>Сүзгә лексик анализ ясау.<br>Мәкальләр, әйтемнәр. | күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне аеру; омоним, синоним, антоним һәм тропларның төп төрләрен тану.<br>Синонимнарның мәгънәви һәм стилистик аермалары. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен; синонимнарны һәм синонимик ояларны; антонимик парларны; омонимнарны чагыштыру. Әдәби телдә һәм гади сөйләм телендә күчерелмә мәгънәле сүзләрнең; әдәби әсәрләрдә һәм фәнни текстларда, уку текстларында синоним, антонимнарның кулланылышын күзәтү. Үз сөйләмеңдә синоним, антоним, бер тематик төркемгә караган сүзләр, омоним, күп мәгънәле сүзләрне куллану. Фразеологик әйләнмәләрне тану. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрне урынлы куллану; сүзгә лекик анализ ясау. Синоним һәм антонимнар сүзлеген файдалану. |
| **16** | **Морфемика һәм сүз** | Лингвистиканың бер бүлеге | Морфемаларны табу, сүзләрне мәгънәсе һәм |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | **ясалышы** | буларак морфемика. **Морфемика (телнең морфемик төзелеше) һәм сүз ясалышы.** Сүз төзелеше һәм ясалышы турында гомуми мәгълүмат. Телнең иң кечкенә берәмлеге буларак морфема. Тамыр һәм аффикс. Тамырдаш сүзләр. Аффикслар ярдәмендә яңа сүзләр ясалышы. Төрле сүз төркеменә караган сүзләр ясалышында аффиксларның роле.<br>Аффикслар, аффикс төрләре: сүз ясагыч, форма ясагыч һәм бәйләгеч аффикслар.<br>Татар телендә сүз ясау формалары. Тамыр сүзләр. Ясалма сүзләр. Кушма сүзләр, кушма сүзләрнең структур төрләре: кушма, тезмә, парлы сүзләр. Татар һәм рус телләрендә сүз төзелешендәге төп аермалар. Морфемик анализ һәм сүз ясагыч | төзелеше, грамматик анализ нигезендә морфемаларга бүлү; сүзнең морфемик составына характеристика бирү, морфемик составка нигезләнеп, сүзнең лексик мәгънәсенә ачыклык кертергә; сүзнең морфемик төзелешен һәм аның ясалыш ысулын; сүзнең лексик мәгънәсен һәм шул сүз төзелгән сүз ясалыш моделен чагыштыру; чыганак нигез һәм сүз ясагыч морфеманы бүлеп чыгарып, телдән һәм язмача морфемик һәм сүз ясалыш анализ ясау; өйрәнелгән сөйләм сүз төркемнәренә караган сүзләрнең сүз ясалыш ысулларын аеру; сүз ясалыш анализы нигезендә морфемаларны бүлеп чыгару; морфемик һәм сүз ясагыч анализ ясау. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | | анализ. | |
| **6** | **Морфология** | Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре.<br>Сүз төркеме буларак исем, аның гомуми мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре.<br>Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр.<br>Сүз төркеме буларак сыйфат, аның гомуми мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функциясе.<br>Сүз төркеме буларак фигыль, аның гомуми мәгънәсе, синтаксик функцияләре.<br>Фигыльләрнең төрләнеше.<br>Кабатлау. | Морфологиянең төп төшенчәләрен белү. Сүзнең, Лексик мәгънәсеннән аермалы буларак, грамматик мәгънәсе үзенчәлекләрен аңлау.<br>Исем сүз төркеменең гомуми мәгънәсен, морфологик үзлекләрен, аның синтаксик ролен анализлау һәм характеристика бирү.<br>Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрне тану.<br>Сыйфат сүз төркеменең гомуми мәгънәсен, морфологик үзлекләрен, аның синтаксик ролен анализлау һәм характеристика бирү.<br>Сыйфатларны исемнәр белән дөрес куллану.<br>Фигыль сүз төркеменең гомуми мәгънәсен, морфологик үзлекләрен, аның синтаксик ролен анализлау һәм характеристика бирү.<br>Исем, сыйфат, фигыль сүз төркеменә морфологик анализ ясау.<br>Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау. |
| **6** | **Синтаксис** һәм **пунктуация** | Грамматиканың бер бүлеге буларак синтаксис.<br>Синтаксик берәмлеге буларак | Сүз төркемнәренең синтаксик ролен билгеләү; тезүче һәм ияртүче теркәгечләр ярдәмендә дөрес итеп кушма җөмләләр төзү; текстта җөмләләрне |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | | сүзтезмә.<br>Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге буларак җөмлә.<br>Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре: хикәя, боерык (тойгылы) һәм сорау җөмләләр.<br>Эндәш сүзләр, аларның функцияләре.<br>Әңгәмәдәшкә йогынты ясау, сөйләмгә бәя бирү чагылышы буларак кереш конструкцияләр (сүзләр, сүзтезмәләр).<br>Җөмлә азагында тыныш билгеләре. Гади җөмләдә тыныш билгеләренең куелышы белән бәйле пунктуация кагыйдәләре.<br>Кабатлау. | бәйләү өчен тезүче теркәгечләрне файдалану; сөйләмдә җөмләдәге дөрес интонацияне саклау.<br>Синтаксисның төп берәмлекләрен тану (сүзтезмә, җөмлә, текст); структур-мәгънәви ясалыш һәм функциональ үзенчәлекләр күзлегеннән чыгып, сүзтезмәләрнең төрләрен һәм җөмләләрне анализлау; җөмләнең грамматик нигезен табу; җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен тану.<br>Пунктуациянең төп кагыйдәләрен белү. |
| 4 | Стилистика һәм сөйләм | Телдән һәм язма сөйләм турында | Мәктәптә татар телен өйрәнү дәверендә |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | культурасы | төшенчә. Сөйләмдә синоним, антоним һ.б. урынлы куллану. Сөйләм культурасы үсеше һәм стильләрне камилләштерүдә синтаксик синомнарның роле. Әдәби тел төшенчәсе. Телдән һәм язма әдәби телгә карата куелган таләпләр турында гомуми төшенчә. Сөйләмдә төрле лексик чараларны (синоним, антоним, калька, фразеологик әйтелмәләр, мәкальләр һәм әйтемнәр) куллану мөмкинлеге. Төрле жанр һәм стильгә караган текстлар белән эшләү. Текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. | үзләштерелгән татар әдәби теленең төп нормаларын белү; аларны төрле коммуникатив юнәлешләрдәге телдән һәм язма сөйләмдә саклау; культуралы кеше өчен дөрес сөйләшүнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын аңлау, туган теленә хөрмәт белән карау; әдәби телнең төп кагыйдәләре һәм өйрәнелгән сүзлек запасы кысаларында басым куелышын үзләштерү. |
| 3 | Кабатлау.<br>Тест эшләү. | | |
| 3. ЭТНОМӘДӘНИ КОМПЕТЕНЦИЯ ЯСАЛЫШЫН ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН ЭЧТӘЛЕК (8 сәг) | | | |
| **5** | **Сөйләм культурасы** | Лингвистиканың бер бүлеге | Үзеңнең этник нигезләрең, милли кыйммәтләр, |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | | буларак сөйләм культурасы. Тел нормалары, аның функцияләре. Әдәби телнең төп кагыйдәлере: орфоэпик, лексик, грамматик, дөрес язу кагыйдәләре. Кагыйдә вариантлары. Сөйләм хаталары. Татар теленең һәм сөйләм культурасының лексик байлыгы. Татар теленең сөйләм этикеты. Коммуникация төренә карап сөйләм этикетының тиешле кагыйдәләрен куллану. Татар сөйләм этикеты: исәнләшү, саубуллашу, котлау ситуацияләре этикеты. Диалогларда аралашу – эш-хәрәкәткә өйдәү. Телдә халык мәдәнияте һәм тарихы чагылышы.<br>Фольклор һәм әдәби әсәрләрдә милли-мәдәни компонентлы тел берәмлекләре. | гореф-гадәт, мәдәният турындагы белемнәргә таянып, уку вакытында һәм көндәлек тормышта, исәнләшү, саубуллашу, котлау этикеты күзаллау. Шәхескә карата хөрмәт, әйләнә-тирәдәгеләргә дустанә мөнәсәбәт, иҗтимагый танылуга ихтыяҗ нигезендә үз сөйләмеңдә сөйләм этикетын дөрес куллану. |
| **3** | **Тел һәм мәдәният** | Телдә татар халкының тарихы, | Хәзерге татар әдәби теле һәм гади сөйләмгә хас |

| Сәгатьләр саны | Бүлек исеме , тема | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|---|---|
| | | мәдәнияте һәм Россиядә яшәүче башка халыклар белән бәйләнешенең чагылышы.<br>Текстта милли-мәдәни компонентлы мәгънәгә ия булган тел берәмлекләрен билгеләү һәм аларның мәгънәләрен аңлатмалы, этимологик, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге һ.б. сүзлекләр ярдәмендә аңлата белү. | булган кагыйдәләрне үтәп, диалогларда катнашу, максат, бурыч һәм аралашу ситуацияләренә бәйле төрле коммуникатив юнәлештәге чыгышлар ясау; башка кешеләр белән аралашу вакытында сөйләм чыганакларын сайлап алу һәм куллану (парлы диалог, кечкенә төркемнәрдә диалог һ.б.; текстларны адекват кабул итү, интерпретация ясау һәм текстка карата үз фикереңне белдерү; текст билгеләрен белү; тема, төп фикер һәм иң мөһим сүзләрне билгеләү; тексттагы микротемаларны билгеләү, аларны абзацларга бүлү; абзацлар һәм текстны композицион элементларын белү (кереш, төп өлеш, йомгак); текст өлешләре һәм җөмлә кисәкләре бәйләнешенең лексик һәм грамматик чараларын табу. Татар теленең Россия тарихы, мәдәнияте белән бәйләнешен аңлау; өйрәнелә торган текстларда милли-мәдәни компонентлы тел берәмлекләрен табу. Этимологик сүзлек файдалану. |

**6 класс**

| **Барлык сәгатьләр саны** | **105 сәг.** |
|---|---|
| Коммуникатив компетенция | 25 сәг. |
| Тел һәм лингвистик компетенция | 72 сәг. |
| Этномәдәни компетенция | 8 сәг. |

| **Сәгатьләр саны** | **Бүлек, тема атамасы** | **Төп эчтәлеге** | **Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы** |
|---|---|---|---|
| 1. КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯ БУЛДЫРУНЫ ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН ЭЧТӘЛЕК (25 сәг) | | | |
| **2** | Сөйләм һәм аралашу | Аралашу шартлары. Монолог төрләре: хикәяләү, сурәтләү, фикерләү.<br>Сораштыру диалогы, диалог – эш-хәрәкәткә чакыру, этәргеч. Төрле | Диалогик һәм монологик сөйләм үзенчәлекләрен белү. Диалогның берничә төренә ия булу (этикет диалогы, сораштыру, эш-хәрәкәткә чакыру диалогы). Үз сөйләмендә типик аралашу ситуацияләре шартларына туры килә торган |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | төр диалоглар тиңдәшлеге. | диалог төрләрен куллану. Диалогик сөйләм үрнәкләрен чагыштыру. |
| 4 | **Сөйләм эшчәнлеге** | Сөйләм эшчәнлеге төрләре буларак тыңлап аңлау, уку, язуның төп үзенчәлекләре. Сайлап алу, танышу, детальле тыңлап аңлау. Телдән сөйләнә торган монологны аңлау эффиктивлыгын арттыра торган ысуллар. Уку культурасы. Телдән сөйләүнең төп үзенчәлекләре. Күргән, ишеткән мәгълүматны аралашу шартлары буенча кыскартып, сайлап алып, җентекләп сөйләү. Язма сөйләмнең төп үзенчәлекләре. Укылган, тыңланылган текстны тулы, кыскача, сайлап алып язу. | Сөйләм эшчәнлегенең төп төрләре һәм аларның үзенчәлекләре турында күзаллау булдыру. Тыңлап аңлауның төрле төрләреннән файдалану. Күреп яки ишетеп кабул ителгән текстта төп һәм өстәмә мәгълүматны аера алу. Укып, ишетеп кабул ителгән текстны кыскача, сайлап алып яки җентекләп сөйләп бирү. Актуаль социаль-мәдәни, көнкүреш, уку-укыту темаларына телдән һәм язмача монологик һәм диалогик текстлар төзү. |
| 2 | **Текст.** | Текстның төп үзлекләре. Текст структурасы. Текстның мәгънәви, композицион бөтенлеге һәм төзеклеге. Тема, тексттагы төп | Текст үзлекләрен белү. Текстның темасын, төп фикерен, иң мөһим сүзләрен, җөмләләрнең бәйләнеш төрләрен билгеләү; сөйләм өлешләрен һәм җөмләләрне бәйли торган мәгънәви, лексик, |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | фикер. Текстның микротемасы. Текст өлешләрен һәм җөмләләрне үзара бәйли торган лексик, грамматик һәм мәгънәви чаралар. Тексттагы төп һәм өстәмә мәгълүмат. План (катлаулы), аннотация. Сөйләмнең функциональ-мәгънәви тибы буларак сурәтләү, аның үзенчәлекләре (предмет, халәт, процесны сурәтләү); сөйләмнең башка функциональ-мәгънәви кисәкләре белән тиңдәшлеге. | грамматик чаралар.<br>Текстны тема бердәмлеге, мәгънәви бөтенлек, язу эзлеклелеге, лексик һәм грамматик бәйләүче чараларның урынлы кулланылуы күзлегеннән чыгып анализлау һәм характеристика бирү.<br>Текстның микротемасын билгеләү, аны абзацларга бүлү; абзацның һәм текстның композицион элементларын белү (кереш, төп өлеш, йомгак). |
| 2 | **Телнең функциональ төрлелеге.** | Телнең функциональ төрлелеге: гади сөйләм, рәсми стиль, фәнни стиль, публицистик стиль.<br>Гади сөйләмгә хас булган тел-сурәтләү чаралары, сөйләм максаты, типик сөйләм ситуацияләре, кулланылу даирәсе.<br>Гади сөйләмнең төп жанрлары: | Текстның билгеле-бер функциональ теленә карау-карамавын билгеләү. Сөйләмне эчтәлек, стилистик үзенчәлекләр һәм тел-сурәтләү чаралары буенча чагыштыру һәм тәңгәлләштерү.<br>Гади сөйләмнең үзенчәлекләрен билгеләү<br>Яшьтәшләрең алдында чыгыш ясау, аралашу ситуациясе һәм максаты нигезендә әңгәмә алып бару. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | хикәя, әңгәмә.<br>Рәсми стильгә хас булган тел-сурәтләү чаралары, сөйләм максаты, типик сөйләм ситуацияләре, кулланылу даирәсе.<br>Рәсми стильнең төп жанрлары: гариза, аның үзенчәлекләре.<br>Фәнни стильнең төп жанрлары: аннотация, аның үзенчәлекләре.<br>Публицистик стильнең төп жанрлары: чыгыш, аның үзенчәлекләре. | Мәгълүмат белән алмашу өчен электрон почта файдалагну.<br>Интернет мөмкинлекләрен файданып, шәхси көндәлек (блок) алып бару.<br>Аралашу максаты һәм ситуациясеннән чыгып, аннотация, гариза, хикәя язу.<br>Публицистик характердагы зур булмаган доклад белән яшьтәшләрең алдында чыгыш ясау.<br>Аралашу максаты һәм ситуациясеннән чыгып, гариза язу.<br>Коммуникатив таләпләр, тел нормалары күзлегеннән чыгып, үзеңнең һәм башкаларның сөйләмнәрен бәяләү.<br>Сөйләм җитешсезлекләрен, текстны төзәтү. |
| **15** | Контроль диктант (4).<br>Изложение (5).<br>Инша (6) | | Татар теленең орфографик нормаларын саклап, контроль диктант, изложение, инша, инша элементлары кертелгән изложение язу; орфографик, пунктуацион хаталар табу һәм аларны төзәтү. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| 2. ТЕЛ ҺӘМ ЛИНГВИСТИК КОМПЕТЕНЦИЯ БУЛДЫРУНЫ ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН ЭЧТӘЛЕК (72 сәг.) | | | |
| **1** | **Тел турында гомуми мәгълүмат** | Хәзерге татар теленең кулланылыш формалары: әдәби тел, территориаль диалектлар, шәһәр гади сөйләме, билгеле бер һөнәр ияләренә хас булган сөйләм, жаргон | Хәзерге татар теленең кулланылыш формалары турында күзаллау булдыру. Хәзерге татар телнең кулланылыш төрләрен аеру. |
| **8** | **Фонетика һәм графика.** | Сөйләмдә авазлар үзгәреше. Аваз һәм фонема. Татар теленең сузыклар системасы, аларның күләме. Сузык авазлар классификациясе. Татар теленең тартыклар системасындагы үзгәрешләр. Тартыклар ассимиляциясе, ассимиляция төрләре. Татар һәм рус телләрендә сузык һәм тартык авазлар.<br>Татар телендә басым. Татар теленең үз сүзләрендә һәм алынмаларда басым сакланмый | Фонетиканың төп төшенчәләреннән файдалану. Сүзгә фонетик анализ ясау. Сүздә сузык һәм тартыклар өчен көчле һәм көчсез позицияләрне күзаллау. Әлеге билгеләр нигезендә авазларны классификацияләү һәм төркемнәргә бүлү.<br>Басымлы иҗекнең урынын билгеләү, сүз формасы үзгәргәндә басымның үзгәрүен һәм авазларның чиратлашуын күзәтү.<br>Акцентологик күзлектән чыгып караганда, катлаулы тоелган сүзләрдә һәм аларның формаларында басым төшәргә тиешле урынны үзләштерү.<br>Фонтик анализ ясау. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | торган очраклар.<br>Интонация төшенчәсе.<br>Фонетик анализ.<br>Кабатлау. | |
| **4** | **Орфоэпия һәм орфография** | Орфоэпия нормалары турында төшенчә.<br>Орфоэпик сүзлек.<br>Графика һәм орфографика турында төшенчә. Телнең орфографик нормалары.<br>Баш һәм юл хәрефләрне куллану. Сүзне юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре.<br>Сузыкларның дөрес язылышы.<br>Тартыкларның дөрес язылышы.<br>Сүзләрнең бергә, аерым һәм сызыкча аша язылу очракларына бәйле орфографик кагыйдәләр.<br>Орфографик сүзлек. | Орфоэпик сүзлектән куллану; орфографик сүзлектән куллану; орфографик хаталарны табу һәм аларны төзәтү; сүзләрдә үзләштерелгән орфограммаларны табу. Өйрәнелгән орфограммаларга характеристика бирү һәм сүзләрнең язылышын аңлату. Сүзләрнең иҗеккә бүленеш һәм сүзне юлдан юлга күчерү ысулларын аеру, белү.<br>Орфографик, пунктуацион проблемаларны хәл итү өчен орфографик сүзлекләрне һәм дөрес язу буенча белешмәләрне куллану. |
| **10** | **Лексикология һәм фразеология** | Лексикология. Тел берәмлеге буларак сүз. Сүзнең башка тел | Лексикологиянең төп төшенчәләрен үзләштерү.<br>Телнең лексик дәрәҗә берәмлеге буларак сүз |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | берәмлекләреннән аермасы. Татар теленең сүзлек составы: искергән сүзләр, тарихи сүзләр, неологизмнар һәм аларның төрләре.<br>Диалекталь сүзләр. Терминнар һәм һөнәрчелек сүзләре. Жаргон лексикасы һәм аларның кулланылыш үзенчәлекләре.<br>Сүзнең стилистик бизәлеше.<br>Фразеологик әйтелмәләр, аларның мәгънәләре. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрне куллану үзенчәлекләре.<br>Төрле сүзлекләр, аларны төрле эшчәнлектә файдалану.<br>Сүзгә лексик анализ ясау. Кабатлау. | үзенчәлекләрен аңлау.<br>Сүзләрнең гади сөйләмдә, әдәби телдә, публицистик һәм фәнни-популяр текстларда, диалектизмнарның әдәби әсәр телендә кулланылышын күзәтү.<br>Сүзләргә кулланылыш даирәсе һәм стилистик бизәлеше ягыннан характеристика бирү.<br>Мәгънәсе һәм аралашу даирәсе нигезендә лексик чараларны сайлау һәм куллану.<br>Аңлатмалы сүзлектән һәм фразеологик әйтелмәләр сүзлегеннән кирәкле мәгълүматны алу,аны төрле эшчәнлектә куллану.<br>Фразеологиянең төп төшенчәләрен аңлау.<br>Фразеологик әйләнмәләрне аларны билгеләре буенча аеру.<br>Ирекле сүзтезмәләрне фразеологик әйтелмәләрдән аеру. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрне урынлы куллану.<br>Синоним, антоним һәм омонимнар сүзлеген куллану.<br>Сүзгә лексик анализ ясау. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| 6 | **Морфемика һәм сүз ясалышы** | Сүз ясалышы һәм сүз формасы үзгәрү, сүз ясагыч, форма ясагыч һәм бәйләгеч аффикслар.<br>Сүз ясалыш пары, сүз ясалыш чылбыры. Сүз ясалыш оясы.<br>Сүз ясалышының төп ысуллары.<br>Аффикслар ярдәмендә сүз ясалышы.<br>Сүзъясалыш ысулы буларак, сүзләрне кушу. Кушма сүзләр. Сүзләргә морфемик һәм сүз ясагыч анализ ясау.<br>Кабатлау. | Морфемика һәм сүз ясалышының төп төшенчәләрен үзләштерү.<br>Морфеманың башка мөһим тел берәмлекләреннән аермасын аңлау; форма һәм сүз ясалышында морфеманың роле. Морфемаларны тану һәм сүзләрне мәгънәви, грамматик һәм сүз ясагыч анализ нигезендә бүлү; сүзнең морфемик составына характеристика бирү, сүзнең морфемик составына таянып, аның лексик мәгънәсен ачыклау.<br>Морфемика һәм сүз ясалышы өлкәсендәге белемнәрне дөрес язу, шулай ук сүзгә грамматик анализ ясауда куллану. Нигез һәм сүз ясагыч морфеманы аерып чыгарып, телдән һәм язмача морфемик һәм сүз ясалыш анализ ясау; өйрәнелгән сүз төркемнәренә караган сүзләрнең сүз ясалыш ысулларын аеру; сүз ясалыш парлары һәм сүз ясалыш чылбыры төзү.<br>Сүзгә морфемик һәм сүз ясалыш анализ ясау. |
| 25 | **Морфология** | Грамматиканың бер бүлеге буларак морфология. | Морфологиянең төп төшенчәләреннән файдалану.<br>Сүзнең грамматик һәм лексик мәгънәләрен аеру. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
| --- | --- | --- | --- |
| | | Сүз төркемнәре классификациясе. Мөстәкыйль, хәбәрлек һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәре.<br>Мөстәкыйль сүз төркемнәре: исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре.<br>Сүз төркеме буларак исем (кабатлау). Сан, килеш һәм тартым категорияләре.<br>Сүз төркеме буларак, сыйфат (кабатлау). Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфат дәрәҗәләре.<br>Сүз төркеме буларак сан, аның гомумкатегория мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре. Саннарның мәгънә ясалыш ягыннан сан төркемчәләре. Микъдар һәм тәртип саннарының грамматик үзлекләре.<br>Сүз төркеме буларак алмашлыклар, аларның гомумкатегория мәгънәләре, | Исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртеме сүз төркеменең гомуми мәгънәсе, морфологик билгеләрен анализлау һәм характеристика бирә белү, аларның синтаксик функцияләрен билгеләү.<br>Сан сүз төркемнә караган сүзләрне сан мәгънәсе йөрткән башка сүзләрдән аеру.<br>Микъдар, тәртип, җыю саннарын аеру, мисаллар китерү. Кушма саннарны килешләр буенча дөрес төрләндерү һәм аларны сөйләмдә дөрес куллану.<br>Саннарны бирелгән морфологик билгеләр нигезендә төркемнәргә туплау.<br>Алмашлыкларны башка сүз төркемнәре белән чагыштыру һәм тәңгәлләштерү. Зат, сан, тартым, күрсәтү, сорау, билгеләү, юклык алмашлыкларын тану; мисалар китерү.<br>Алмашлыкларны килешләр белән дөрес төрләндерү. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре. Мәгънә һәм грамматик билгеләр буенча алмашлык төркемнәре. Алмашлыкларның төрләнеше.<br>Сүз төркеме буларак фигыль, аның гомумкатегория мәгънәсе, морфологик үзлекләре, синтаксик функцияләре. Фигыльләрнең төрләнеше. Затланышлы фигыль формалары: хикәя фигыль, боерык фигыль, теләк фигыль, шарт фигыль.<br>Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау. | Алмашлыкларны бирелгән морфологик билгеләр буенча төремнәргә туплау; алмашлыкларны текст өлешләрн һәм җөмләләрне бәйләү өчен файдалану; алмашлыкларны кабул ителгән тел нормалары нигезендә куллану.<br>Сүз төркемнәрен аеру; фигыльләрнең үзенчәлекле морфологик билгеләрен белү һәм дөрес күрсәтә белү, фигыльләрне төрләндерә белү.<br>Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау. |
| **12** | Синтаксис һәм пунктуация | Грамматиканың бер өлеше буларак синтаксис.<br>Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге буларак җөмлә. Эмоциональ бизәлеш ягыннан җөмлә төрләре: тойгысыз һәм тойгылы җөмлә. | Җөмлә кырларын, аларны телдән яки язмача тапшыру ысулларын билгеләү.<br>Әйтү максаты һәм эмоциональ бизәлеш ягыннан җөмлә төрләрен билгеләү.<br>Хикәя, тойгылы, сорау, боерык төмләләрнең интонацион һәм мәгънәви үзенчәлекләрен аеру. |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | Аларның интонацион һәм мәгънәви үзенчәлекләре. Җөмләнең грамматик нигезе. Гади һәм кушма җөмләләр. Җөмләнең иярчен кисәкләре: аергыч, тәмамлык, хәл. Җәенке һәм җыйнак җөмләләр. Тиңдәш кисәкле җөмләләр. Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә бәйләүче чаралар. Эндәш сүз, аның функцияләре. Эндәш сүзле җөмләдә басым. Татар телендә тыныш билгеләре. Кабатлау. | Җөмләнең грамматик нигезен табу, гади һәм кушма җөмләләрне тану. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен тану. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру. Тиңдәш кисәкле җөмләләрне тану, аларны дөрес аңлау, телдән һәм язма сөйләмдә куллану. Эндәш сүзләрнең төп функцияләрен аңлау. Эндәш сүзләр кергән җөмләләрне тану һәм дөрес аңлау. Аралашу ситуациясе һәм даирәсе нигезендә, төрле эндәш сүз формалары булган җөмләләр төзү һәм сөйләмдә куллану. Пунктуациянең төп таләпләрен белү. |
| **3** | Стилистика һәм сөйләм культурасы | Сөйләмдә синоним, антонимнарны урынлы куллану. Сөйләм культурасын үстерүдә һәм стильләрне камилләштерүдә синтаксик синонимнарның роле. Сөйләмдә төрле лексик чараларны (синоним, антоним,калька, | Мәктәптә татар телен өйрәнү вакытында үзләшерелгән татар әдәби теленең төп нормаларын белү; аларны төрле коммуникатив юнәлештәге телдән һәм язма аралашу вакытында саклау; культуралы кеше өчен дөрес әйтү нормаларының ни дәрҗәдә мөһим булуын аңлау, туган телгә хөрмәт белән карау; әдәби сөйләмнең |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | фразеологик әйтелмә, мәкаль, әйтем) куллану мөмкинлеге.<br>Төрле жанр һәм стильдәге текстлар белән эшләү. Текстларны татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү. | төп нормаларын һәм өйрәнелгән сүзлек составы кысаларында басымның куелышын үзләштерү. |
| **3** | Кабатлау. Тест эшләү. | | |
| 3. ЭТНОМӘДӘНИ КОМПЕТЕНЦИЯ ЯСАЛЫШЫН ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН ЭЧТӘЛЕК (8 сәг) | | | |
| **15** | **Сөйләм культурасы** | Лингвистиканың бер өлеше буларак сөйләм культурасы.<br>Телдән аралашу этикасы, эффективлыгы, нормативлыгына ирешүнең мәҗбүри шарты буларак, аралашу шарты һәм даирәсе нигезендә тел-сурәтләү чараларын сайлау.<br>Алмашлык, сан, фигыльләрне куллануның орфоэпик, лексик, грамматик, стилистик кагыйдәләре һәм язылыш нормалары. Кагыйдә | Милли кыйммәтләрне, гореф-гадәтләрне, мәдәниятне үзләштерү, үзүсешкә омтылу һәм үзтәрбиягә әзерлек нигезендә культуралы кешенең тел нормаларын саклауның әһәмиятенә төшенүе.<br>Сүз төркемнәрен өйрәнгәндә, әдәби татар теленең төп кагыйдәләрен үзләштерү; аларны телдән һәм язма сөйләмдә саклау, кирәк очракта төзәтмәләр кертү.<br>Үзеңнең һәм башкаларның сөйләмендә татар теленең төп нормалары саклануны анализлау һәм бәяләү.<br>Хәзерге татар әдәби теле нормалары турында |

| Сәгатьләр саны | Бүлек, тема атамасы | Төп эчтәлеге | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре характеристикасы |
|---|---|---|---|
| | | вариантлары.<br>Хәзерге татар теленең норматив сүзлекләре (орфоэпик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, орфографик сүзлек), аларның хәзерге татар әдәби телен үзләштерүдәге роле. | мәгълүмат алу өчен норматив сүзлекләр куллану. |
| **5** | **Тел һәм мәдәният** | Тел һәм мәдәниятнең үзара бәйләнеше. | Татар теленең мәдәният һәм тарих белән бәйләнешен аңлау.<br>Телне өйрәнү ил тарихын һәм мәдәниятен яхшырак белергә ярдәм итә дигән фикерне дәлилли торган мисаллар китерү.<br>Шәхескә хөрмәт, әйләнә-тирәдәгеләргә дустанә мөнәсәбәт, иҗтимагый танылуга ихтыяҗ нигезендә сөйләм кагыйдәләрен уку-укыту эшчәнлегендә һәм көндәлек тормышта урынлы куллану. |

## 7 нче сыйныф

| Барлык сәгатьләр саны | 105 сәг. |
|---|---|
| Коммуникатив компетенция | 25 сәг. |
| Тел һәм лингвистик компетенция | 72 сәг. |
| Этномәдәни компетенция | 8 сәг. |

